ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
УРНЯКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Лесная, д. 44А, п.Урняк,
Арский муниципальный район, 422019

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ҮРНӘК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Урман урамы, 44А йорты, Үрнәк авылы,
Арча муниципаль районы, 422019

Тел. (84366)51-4-93, факс (84366)51-4-93. E-mail: Urn.Ars@tatar.ru

**КАРАР**

**«08» ноябрь 2021 ел** **№16**

«Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Башкарма комитетының 16 август 2021 ел, №11 карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. «Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Башкарма комитетының 16 август 2021 ел, №11 карары белән расланган адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1.5 пунктының 2 - 10 абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Регламентта кулланыла торган федераль мәгълүмат адреслы системасының дәүләт адреслар реестрын алып баруга һәм эксплуатацияләүгә бәйле төшенчәләр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Федераль мәгълүмати адреслар системасы турында һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законга, «Адреслар бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 декабрендәге 1221 номерлы карарына тәңгәл рәвештә кулланыла.»;

1.2. 1.5 пуктның 11 - 17 абзацларын 3 - 9 абзацлар дип санарга;

1.3. 2.6.1 пунктының 4-7 пунктчаларында «Башкарма комитет» сүзен «Төзелгән килешү нигезендә муниципаль районның җирле үзидарә органы яки Башкарма комитет» сүзләренә алмаштырырга;

1.4. 2.6.1 пунктының 8 пунктчасында «Башкарма комитет» сүзен «Төзелгән килешү нигезендә муниципаль районның җирле үзидарә органы яки Башкарма комитет»сүзләренә алмаштырырга;

1.5. 2.6.4 пунктында «Башкарма комитетның структур бүлекчәсе» сүзләрен «Муниципаль районның җирле үзидарә органнары, Башкарма комитет» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында игълан итәргә (pravo.tatarstan.ru), шулай ук «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң (халыкка җиткерелгәннән) үз көченә керә.

Үрнәк авыл җирлеге башлыгы Габделхаков В.Р.